ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 октябрь 2024 ел № 5871

«2025-2028 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тәртибен һәм хокук бозуларны профилактикалауны тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында

Яр Чаллы шәһәрендә җәмәгать тәртибен саклау буенча тормышка ашырыла торган чараларның сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген күтәрү максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасының нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында» 2016 елның 26 декабрендәге 3-ТРЗ номерлы Законы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. «2025-2028 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тәртибен һәм хокук бозуларны профилактикалауны тәэмин итү» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән программаны финанслауны Яр Чаллы шәһәре бюджетының «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13, «Милли иминлек һәм хокук саклау эшчәнлеге өлкәсендә башка мәсьәләләр» 03.14 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына тәэмин итәргә: 2025 ел – 84 641,95 мең сум, 2026 ел – 85 486,19 мең сум, 2027 ел – 85 486,19 мең сум, 2028 ел – 85 486,19 мең сум.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе мөдире Р.К. Шипеевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2024 елның 18 октябрендәге
6871 номерлы карарына
кушымта

«2025-2028 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тәртибен һәм хокук бозуларны профилактикалауны тәэмин итү»
муниципаль программасы

1 бүлек. «2025-2028 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тәртибен һәм хокук бозуларны профилактикалауны тәэмин итү»
муниципаль программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2025-2028 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тәртибен һәм хокук бозуларны профилактикалауны тәэмин итү» муниципаль программасы |
| Программаны эшләү өчен нигез | «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» 2014 елның 2 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасының нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» 2014 елның 24 декабрендәге 4-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында» 2016 елның 26 декабрендәге 3-ТРЗ номерлы Законы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары |
| Программаны төп эшләүчеләр һәм башкаручылар | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе |
| Программаның максаты | 1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җәмәгать тәртибен саклау буенча тормышка ашырыла торган чараларның сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген күтәрү.<br>2. Яр Чаллы шәһәрендә җинаятьчелеккә каршы тору һәм җәмәгать тәртибен саклау нәтиҗәлелеген күтәрү. |
| Программаның бурычлары | 1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җинаятьчелек дәрәҗәсен киметү.<br>2. Хөкем ителгәннәрне иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат итүгә әзерләүне оештыру.<br>3. Шәһәр урамнарында һәм җәмәгать урыннарында кылына торган хокук бозуларны профилактикалау һәм кисәтү эшен камилләштерү.<br>4. Яр Чаллы шәһәрендә хөкем ителгәннәрне социаль адаптацияләү, ресоциализацияләү һәм социаль тернәкләндерү өчен шартлар тудыру. |

<table>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары</td><td colspan="6">2025-2028 еллар</td></tr>
<tr><td rowspan="7">Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="4">Программаны тормышка ашыру еллары</td><td rowspan="2">Тормышка ашыру чорында барлыгы мең сум</td></tr>
<tr><td>2025 ел мең сум</td><td>2026 ел мең сум</td><td>2027 ел мең сум</td><td>2028 ел мең сум</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>84 641,95</td><td>85 486,19</td><td>85 486,19</td><td>85 486,19</td><td>341 100,52</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>Башка чыганаклар</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>84 641,95</td><td>85 486,19</td><td>85 486,19</td><td>85 486,19</td><td>341 100,52</td></tr>
<tr><td>Максатларны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре</td><td colspan="6">Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә түбәндәгеләрне киметү күздә тотыла:<br>1) теркәлгән җинаятьләр саны;<br>2) элек хөкем ителгән затлар тарафыннан кылынган җинаятьләр саны;<br>3) шәһәр урамнарында һәм җәмәгать урыннарында кылына торган җинаятьләр саны.</td></tr>
<tr><td>Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы</td><td colspan="6">Программаның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе гамәлгә ашыра.</td></tr>
</table>

## 2 бүлек. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа методлары белән хәл итү кирәклеген нигезләү

«2025-2028 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җәмәгать тәртибен һәм хокук бозуларны профилактикалауны тәэмин итү» муниципаль программасы (алга таба – программа) Яр Чаллы шәһәрендә җинаятьчелекнең гомуми торышын исәпкә алып эшләнде.

2023 елда Яр Чаллы шәһәре территориясендә 8105 җинаять теркәлгән. Узган ел күрсәткечләре белән чагыштырганда теркәлгән җинаятьләр саны 6% ка (7646 дан 8105 кә кадәр) арткан.

Милеккә каршы җинаятләр саны 2,7% ка (5467 дән 5615 кә кадәр) арткан. Шул исәптән түбәндәгеләр арткан: талаулар саны 16,7% ка (18 дән 21 гә кадәр), банк счетыннан һәм электрон акчаларга мөнәсәбәтле урлаулар саны 16,1% ка (622 дән 722 гә кадәр), карарклык саны 25% ка (1654 тән 2078 гә кадәр), шул исәптән IT-технологияләрдән файдаланып кылынган караклык саны 39,7% ка (1393 тән 1946 га кадәр) арткан.

Җәмәгать урыннарында кылынган җинаятьләр саны 18,3% ка (2997 дән 2450 гә кадәр), шул исәптән урам җинаятьчелеге 25,3% ка (1675 тән 1251 гә кадәр) кимегән. 2023 ел йомгаклары буенча шәһәр урамнарында кылынган җинаятьләр арасыннан аңлы рәвештә сәламәтлеккә авыр зыян салу 72,7% ка (11 дән 19 га кадәр), аңлы рәвештә сәламәтлеккә уртача авырлыктагы зыян салу 24,0% ка (25 тән 31 гә кадәр), аңлы рәвештә сәламәтлеккә җиңелчә зыян салу 20% ка (20 дән 24 кә кадәр) арту күзәтелә.

Ел йомгаклары буенча, элек хөкем ителгән җинаять кылучы затларның саны 1,9% ка (899 дан 882 гә кадәр) кимү күзәтелә, аларның чагыштырма авырлыгы 2,3% ка (35,4% тан 37,7% ка кадәр) арткан.

Бүгенге көндә рецидивның өлеше шактый югары саклана, бу исә яшәешенә бәйле рәвештә чарасызлыктан милек җинаятьләре кылуга бара торган элек хөкем ителгән затлар белән җитәрлек дәрәҗәдәге нәтиҗәле эш булмауны күрсәтә.

Шулай ук «элек җинаятьләр кылган» категориясендәге җинаять җаваплылыгына тартылган затлар саны 2,1% ка (1669 дан 1634 кә кадәр) кимегән, аларның чагыштырма авырлыгы 4% ка (65,8% тан 69,8% ка кадәр) арткан.

Югарыда күрсәтелгән фактлар Яр Чаллы шәһәрендә хокук бозуларны профилактикалау проблемаларын хәл итүдә алга таба да максатчан программа ысулын куллану зарурлыгын күрсәтә.

## 3 бүлек. Программаның максатлары һәм бурычлары

Программаның максаты булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җәмәгать тәртибен саклау буенча гамәлгә ашырыла торган чараларның сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген арттыру тора.

Программаның төп бурычлары булып тора:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җинаятьчелек дәрәҗәсен киметү;

2) хөкем ителгәннәрне irектән мәхрүм итү урыннарыннан азат итүгә әзерләүне оештыру;

3) шәһәр урамнарында һәм җәмәгать урыннарында хокук бозуларны профилактикалау һәм кисәтү эшен камилләштерү;

4) Яр Чаллы шәһәрендә хөкем ителгәннәрне социаль адаптацияләү, ресоциализацияләү һәм социаль тернәкләндерү өчен шартлар тудыру.

## 4 бүлек. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары

Программаны тормышка ашыруның арадаш һәм ахыргы нәтиҗәләрен бәяләү өчен нәтиҗәлелекне бәяләүнең түбәндәге индикаторлары файдаланыла:

| № т/б | Индикаторларның исеме | Чыганаклар |
|---|---|---|
| 1. | Теркәлгән җинаятьләр саны | Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе |
| 2. | Элек хөкем ителгән затлар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең чагыштырма авырлыгы | |
| 3. | Җәмәгать урыннарында кылынган җинаятьләр саны | |
| 4. | Шәһәр урамнарында кылынган җинаятьләр саны | |

## 5 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

2025-2028 елларга программаны финанслау күләме 341 100,52 мең сум тәшкил итә, шул исәптән программаны тормышка ашыру еллары буенча: 2025 ел – 84 641,95 мең сум, 2026 ел – 85 486,19 мең сум, 2027 ел – 85 486,19 мең сум, 2028 ел – 85 486,19 мең сум.

## 6 бүлек. Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеге Яр Чаллы шәһәрендә җинаятьчелек дәрәҗәсе кимү нигезендә бәяләнә.

Программаны тормышка ашыру түбәндәгеләрне киметергә мөмкинлек бирәчәк:

1) теркәлгән җинаятьләр саны;

2) элек хөкем ителгән затлар тарафыннан кылынган җинаятьләр саны;

3) шәһәр урамнарында һәм җәмәгать урыннарында кылынган җинаятьләр саны.

## 7 бүлек. Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | | Финанслау (мең сум) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2024 (нигез) | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| Максат: Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җәмәгать тәртибен саклау буенча гамәлгә ашырыла торган чараларның сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген арттыру | | | | | | | | | | | | |
| 1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җинаятьчелек дәрәҗәсен киметү | | | | | | | | | | | | |
| 1.1. Массакүләм мәгълүмат чараларында һәм транспортта төрле җинаятьләрне һәм хокук бозуларны профилактикалау темасына социаль реклама, социаль аудио-, видеороликлар трансляцияләүне оештыру | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | атна саен | Теркәлгән җинаятьләр саны, берәмлек | 8100 | 8085 | 8065 | 8045 | 8025 | Финанслау таләп ителми | | | |
| 1.2. Хокук бозуларны профилактикалау һәм җинаятьчелеккә каршы тору мәсьәләләре буенча халык белән очрашулар оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | 2025-2028 | | | | | | | Финанслау таләп ителми | | | |
| 1.3. Алкогольле һәм спиртлы продукциянең легаль булмаган әйләнешен кисәтүгә, контрафакт һәм | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрләккә ярдәм күрсәтү идарәсе | ел дәвамында | | | | | | | Финанслау таләп ителми | | | |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | | Финанслау (мең сум) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2024 (нигез) | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| фальсификацияләнгән продукцияне әйләнештән алуга юнәлдерелгән профилактик чараларны гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | | | |
| 2. Хөкем ителгән затларны иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат итүгә әзерләүне оештыру (җәмгыятьтән изоляцияләмичә хөкем ителгәннәрне һәм «Татарстан Республикасы буенча җәзаларны үтәү Федераль хезмәтенең җинаять-башкарма инспекциясе» ФКУ (алга таба – ЖБИ) Яр Чаллы шәһәре филиалларында исәптә торучы затларны ресоциализацияләү) | | | | | | | | | | | | |
| 2.1. Мәҗбүри һәм төзәтү эшләре рәвешендә җинаять җәзасы үтәлә торган оешмаларның төрләрен һәм исемлеген актуальләштерү | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | ел саен | Элек хөкем ителгән затлар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең чагыштырма авырлыгы, % | 37,7% | 37,6% | 37,5% | 37,4% | 37,3% | Финанслау таләп ителми | | | |
| 2.2. ЖБИ хезмәткәрләре белән берлектә җәмгыятьтән изоляцияләмичә хөкем ителгәннәр белән тематик дәресләр, тренинглар үткәрү | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | ел дәвамында | | | | | | | Финанслау таләп ителми | | | |
| 2.3. ЖБИдә исәптә торучы хөкем ителгәннәрне һөнәри укытуны һәм һөнәри әзерләүне оештыру | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | ел дәвамында | | | | | | | Финанслау таләп ителми | | | |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | | Финанслау (мең сум) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2024 (нигез) | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| 2.4. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны эшкә урнаштыру мәсьәләләре буенча ярдәм итүне оештыру | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрләккә ярдәм күрсәтү идарәсе, Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | ел дәвамында | | | | | | | Финанслау таләп ителми | | | |
| 3. Шәһәр урамнарында һәм җәмәгать урыннарында хокук бозуларны профилактикалау һәм кисәтү эшен камилләштерү | | | | | | | | | | | | |
| 3.1. Җәмәгать тәртибен, куркынычсызлыкны тәэмин итү һәм хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләрен хәл итү буенча Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклау пунктлары турында» 2015 елның 25 апрелендәге 33-ТРЗ номерлы Законы кысаларында хезмәттәшлекне оештыру | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре, Башкарма комитет карамагындагы җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү идарәсе | даими | Җәмәгать урыннарында кылынган җинаятьләр саны, берәмлек | 2450 | 2430 | 2410 | 2390 | 2370 | Финанслау таләп ителми | | | |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | | Финанслау (мең сум) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2024 (нигез) | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| 3.2. Җәмәгать тәртибен саклау пунктларын (алга таба – ҖТСП) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 30 маендагы 388 номерлы Карары белән расланган ҖТСП төзүнең тәкъдим ителгән критерийларына туры китерү | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | 2025-2028 | | | | | | | Финанслау таләп ителми | | | |
| 3.3. Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 4-ТРЗ Законы кысаларында гражданнарны ирекле халык дружиналарына җәлеп итү, яшьләр, шул исәптән | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | даими | Шәһәр урамнарында кылынган җинаятьләр саны, берәмлек | 1251 | 1231 | 1211 | 1191 | 1171 | Финанслау таләп ителми | | | |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | | Финанслау (мең сум) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2024 (нигез) | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| студентлар һәм эшче яшьләрнең хокук саклау хәрәкәтен үстерү буенча эшне дәвам итәргә | | | | | | | | | | | | |
| 3.4. Массакүләм мәгълүмат чараларында җәмәгать тәртибен саклауда ирекле катнашучы затларның уңай эш тәҗрибәсен пропагандалауны гамәлгә ашыру | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | ел дәвамында | | | | | | | Финанслау таләп ителми | | | |
| 3.5. Халык дружиначыларын хокукый һәм махсус әзерләү буенча тематик, планлы инструктажлар оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | ярты ел саен | | | | | | | Финанслау таләп ителми | | | |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | | Финанслау (мең сум) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2024 (нигез) | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| 3.6. «Яр Чаллы шәһәренең иң яхшы халык дружинасы» һәм «Яр Чаллы шәһәренең иң яхшы халык дружиначысы» конкурсларын үткәрү | Башкарма комитет карамагындагы җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү идарәсе | декабрь ел саен | | | | | | | 30,0 | 30,0 | 30,0 | 30,0 |
| 3.7. ҖТСПны карап тоту | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | 2025-2028 | | | | | | | 84 441,95 | 85 286,19 | 85 286,19 | 85 286,19 |
| 3.8. «Закон территориясе» китабын бастырып чыгару | Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе | һәр елның 1 кварталы | | | | | | | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 |
| 3.9. «Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» шәһәр премиясе белән бүләкләүне үткәрү | Башкарма комитет карамагындагы җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү идарәсе | ярты елга 1 тапкыр | | | | | | | 150,0 | 150,0 | 150,0 | 150,0 |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | | Финанслау (мең сум) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2024 (нигез) | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| 3.10. Яр Чаллы шәһәрендә җәмәгать тәртибен саклау буенча мәктәп, яшьләр һәм студентлар формированиеләре спартакиадаларын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | апрель ел саен | | | | | | | Финанслау таләп ителми | | | |
| 3.11. Җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр, студентлар һәм мәктәп формированиеләр енең республика слетларында һәм конференцияләрен дә катнашу | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | даими | | | | | | | Финанслау таләп ителми | | | |
| 3.12. Җәмәгать тәртибен саклау буенча ел саен үткәрелә торган иң яхшы яшьләр, эшче, студентлар һәм мәктәп формированиеләре нең республика конкурсында катнашу | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | сентябрь ел саен | | | | | | | Финанслау таләп ителми | | | |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | | Финанслау (мең сум) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2024 (нигез) | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| 3.13. Җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр, студентлар һәм мәктәп формированиеләре әгъзалары өчен сәламәтләндерү лагерьларында ел саен профильле сменалар оештыру | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | май ел саен | | | | | | | Финанслау таләп ителми | | | |
| Барлыгы: | | | | | | | | | 84 641,95 | 85 486,19 | 85 486,19 | 85 486,19 |

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы

Г.А. Шәфыйкова